**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 февраль № 121

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 31 июль, 533 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчаның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары белән бергә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча бүтән норматив хокукый актларны эшли һәм тормышка ашыра;»;

3.3.2 пунктчада:

өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә, дәүләт экология мониторингы бердәм системасының өлеше булган Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохит торышын күзәтүнең территориаль системасын формалаштыру һәм аның эшләвен тәэмин итү хокук белән дәүләт экология мониторингын (дәүләт әйләнә-тирә мохит мониторингын) гамәлгә ашыруда катнаша;»;

җиденче абзацта «халыкны мәгълүмат белән» сүзләрен «мәгълүматтан файдалана алу» сүзләренә алмаштырырга;

текстка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«атмосфера һавасын дәүләт мониторингын оештыруда һәм үткәрүдә катнаша.»;

3.3.3 пунктчаның унынчы абзацы үз көчен югалаткан дип танырга;

3.3.5 пунктчаның өченче абзацы үз көчен югалаткан дип танырга;

3.3.7 пунктчада:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төбәк дәүләт экология күзәтчелеге башкарылырга тиеш объектларда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының хуҗалык һәм (яки) бүтән эшчәнлеге процессында калдыклар барлыкка килә торганнарының хәбәр итү тәртибендә тапшыра торган калдыклар барлыкка килү, аларны юк итү, зарарсызландыру, урнаштыру турында хисапларны кабул итүне гамәлгә ашыра һәм аны тапшыру һәм тикшерүдә тоту тәртибен билгели;»;

текстка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«төбәк дәүләт экология күзәтчелеге башкарылырга тиеш объектларда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан тыш) процессында калдыклар барлыкка килә торган хуҗалык һәм (яки) бүтән эшчәнлегенә карата кулланылышта калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларның урнаштыруга лимитларны, аларны эшкәртү һәм раслау тәртибен билгели.»;

3.3.9 пунктчаның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.11 пунктчаның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фондын һәм геология һәм республиканың җир асты байлыкларыннан файдалану буенча санлы мәгълүмат банкын төзүне һәм алып баруны гамәлгә ашыра, хуҗасы Татарстан Республикасы булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматтан файдалану тәртибен һәм шартларын билгели;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\121.docx